| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.06.2025 ел Алабуга шәһәре № 442

Алабуга муниципаль районы Советының «2025 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) раслау турында» 2024 елның 26 декабрендәге 403 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Алабуга муниципаль районы Советының 2009 елның 22 декабрендәге 257 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «2025 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) раслау турында» 2024 елның 26 декабрендәге 403 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Фаразлау планының (программаның) 2 бүлегенең 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле пунктча белән тулыландырырга:

1.2.

| № т/б | Исеме | Урнашкан урыны | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Билгеләнеше |
|---|---|---|---|---|
| 18 | Фельдшерлык-акушерлык пункты һәм җир кишәрлеге | Алабуга районы, Ядегәр авылы, Тукай ур., 8 нче йорт | 16:18:150101:510<br>16:18:090201:37 | торак булмаган бина |

3. Әлеге карар «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Интернет» челтәрендәге Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга һәм рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис урынбасары Р.З. Шиһапов